СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

29.04.2020 с. Верхний Услон № 57-659

2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чорында керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүмат тапшыру хакында

«2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр хисап чорында керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында» Татарстан Республикасы Президентының 2020 елның 24 апрелендәге УП-250 номерлы Указы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы Советы
карар итте:

1. “Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында, шулай ук Югары Ослан муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында” Югары Ослан муниципаль районы Советының 2014 елның 17 ноябрендәге 51- 499 номерлы карары һәм шулай ук “Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы Нигезләмәне раслау хакында” Югары Ослан муниципаль районы Советының 2019 елның 30 сентябрендәге 49-561 номерлы карары белән каралган 2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чорында керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар 2020 елның 1 августына кадәр тапшырыла.

2. Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетына 2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар бирү срогын да кертеп, 2020 елның 1 августына кадәр озайтырга.

3. Шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарына тәкъдим итәргә:

- муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан 2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чорында керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшырганда әлеге карарга таянып эш итәргә;

- муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре тарафыннан 2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр хисап чорында керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүмат тапшыру вакытын 2020 елның 1 августына кадәр озайтырга.

4. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль район
Башлыгы М. Г. Зыятдинов